МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.09.2018 Казан ш. № 906

ТР Юстиция министрлыгында 2018 елның 23 октябрендә 4936 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушытада бирелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр в.б. Н.В. Бутаева

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.09.2018 № 906 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 26 декабрендәге 737 номерлы боерыгы белән расланган Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Инвалид бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын төзегәндә һәм аны биргәндә Татарстан Республикасының халыкка комплекслы социаль хезмәт күрсәтү үзәкләренең өйдә социаль хезмәт күрсәтү бүлекләре катнаша.»;

1.4 пунктның 1.4.1 һәм 1.4.2 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Идарәнең (бүлекнең) урнашу урыны, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүматлар шушы Регламентка белешмәлек кушымтада, Министрлыкның рәсми сайтында - http://mtsz.tatarstan.ru күрсәтелде.

Идарәнең (бүлекнең) эш графигы көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Идарәнең (бүлекнең) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.4.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә алынырга мөмкин:

1) Идарәләрдә (бүлекләрдә) урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.8, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Идарәгә (бүлеккә), Министрлыкка (mtsz@tatar.ru) язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.»;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2006 елның 29 декабрендәге 256-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2007, № 1, 19 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 52, 7007 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – РФ Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеген раслау турында» 2016 елның 30 апрелендәге 831-р номерлы боерыгы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 20, 2844 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Ана (гаилә) капиталы акчаларын (акчаларының бер өлешен) Инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә мондый товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән юнәлтү кагыйдәләре турында» 2016 елның 30 апрелендәге 380 номерлы карары белән расланган Ана (гаилә) капиталы акчаларын (акчаларының бер өлешен) Инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарларга һәм хезмәт күрсәтүләргә мондый товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга чыгымнарны компенсацияләү юлы белән юнәлтү кагыйдәләре (алга таба – № 380 кагыйдәләр)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 20, 2828 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалид баланы тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасы нигезендә инвалид балаларны җәмгыятькә социаль яраклаштыру һәм кертеп җибәрү өчен билгеләнгән товарларны һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып алуга ана (гаилә) капиталы акчаларыннан файдалануга гражданнарның хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү буенча эшләрне оештыру турында» 2016 елның 16 июнендәге 296 номерлы боерыгы (алга таба – 296 номерлы боерык) (Россия Федерациясенең хезмәт һәм социаль законнары бюллетене, 2016, № 7);

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2014 елның 18 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республиксы Законы (Татарстан Дәүләт Советы җыелма басмасы, 2014, № 12, 1361 ст.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга инвалид-бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибе турында» 2016 елның 04 октябрендәге 568 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга инвалид-бала өчен сатып алынган товар барлыгын тикшерү актын бирү тәртибе (алга таба – № 568 тәртип) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2016, 27 октябрь).»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Әлеге Регламентта «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы, «Балалы гаиләләргә дәүләт ярдәменең өстәмә чаралары турында» 2006 елның 29 декабрендәге 246-ФЗ номерлы, «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 елның 28 декабрендәге 442-ФЗ номерлы федераль законнарда билгеләнгән мәгънәләрендәге

төшенчәләр һәм терминнар, шулай ук түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 ст. 1 п.). Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.»;

2 бүлектә:

2 бүлектә 2.12 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артырга тиеш түгел.»;

2 бүлектә 2.13 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

2 бүлектәге 2.15 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин»;

4 бүлектә:

4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Идарә (бүлек) белгечләре тарафыннан Реламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләренең саклануын һәм үтәлүен агымдагы тикшереп тору Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламентның нигезләмәләре саклануына һәм үтәлүенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла.»;

4.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын тикшерүдә тоту Министрлык аппараты бүлегенең әлеге контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле булган һәм Идарәнең (бүлекнең) вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә торган вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

5 бүлектә:

аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органнарның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта:

беренче абзацта «дәүләт хезмәтен алучылар» сүзләрен «мөрәҗәгать итүчеләр» сүзләре белән алмаштырырга;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамәне теркәү срогы бозылганда;»;

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә.»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чорларын яисә тәртибен бозу;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул иткәндә яисә яисә, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән яки документларны яки мәгълүматны таләп иткәндә.»;

5.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәткәренең (учреждение белгеченең), дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән чоры бозылганда, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы (учреждениедәге) вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.5 һәм 5.6 пунктларның көчен югалтуын танырга;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Шушы пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта җавапта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай

ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңламтамалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

Кушымтаның (белешмәлекнең) 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органнары

| Территориаль орган аталышы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-11-53 | 422230, Әгерҗе ш.,<br>Карл Маркс ур., 11а<br>Agreez.Usz@tatar.ru |
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423330, Азнакай ш.,<br>Болгар ур., 9<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-92-74<br>2-92-72 | 423060, Аксубай ш.т.п.,<br>Совет ур., 4 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав.,<br>Юбилей ур., 45.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.п.,<br>Казаков ур., 8<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-80 | 422870, Базарлы Матак ав.,<br>Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе | (8553)<br>32-45-50<br>43-82-15 | 423452, Әлмәт ш.,<br>К.Цеткин ур., 54а<br>Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-11-84<br>2-10-81<br>2-10-80 | 422350, Апас ав.,<br>Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Арча муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | 422750, Олы Әтнә ав.,<br>Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81 | 423930, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78<br>2-42-09<br>2-50-57<br>2-40-60 | 422250, Балтач ав.,<br>Һ.Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85594)<br>6-55-70<br>6-50-44 | 423230, Бөгелмә ш.,<br>Стрелочная ур., 1 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-55-29 | 422430, Буа ш.,<br>Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |
| Югары Ослан муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-22-76 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медшәһәрчек, 21а й.<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84365)<br>7-47-69<br>7-47-89<br>2-32-52 | 422700, Биектау тимер юл ст. пос., Мәктәп ур., 19<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52<br>2-30-07 | 422470, Иске Чүпрәле ав.,<br>Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-86-91<br>7-84-66 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-09-76<br>7-10-64 | 423520, Зәй ш., Рәфыйков ур., 10<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| | 3-26-89 | |
| Яшел Үзән муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>4-22-97<br>4-16-62 | 422540, Яшел Үзән ш.,<br>К.Маркс ур., 57В<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-15-57<br>2-11-12 | 422330, Зур Кайбыч ав., Кояшлы бульвар ур., 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-69 | 422820, Кама Тамагы ш.т.п.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.,<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-47-31<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче май ур., 35.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>5-50-03<br>6-02-26 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Гагарин ур., 51 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36<br>3-19-69 | 422192, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |
| Менделеевск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00 | 423650, Менделеевск ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59<br>3-19-08 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегендәге социаль яклау идарәсе | (8552)<br>34-48-48<br>34-41-28<br>34-09-76 | 423805, Чаллы ш., Х.Туфан проспекты, 23 й.<br>Usz.Chelny@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89<br>45-35-02<br>45-43-88 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык проспекты, 60<br>Usz.nizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-41-18<br>2-41-42 | 423190, Яңа Чишмә ав.,<br>Ленин ур., 93 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-81<br>2-39-88 | 423040, Нурлат ш.,<br>Пушкин ур., 46 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72<br>3-02-78 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 442650, Балык Бистәсе ш.т.п.,<br>Завод ур., 6а<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-28-55<br>2-28-11 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.п.,<br>Закир Йосыпов ур., 7 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-49-87<br>2-44-37 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-08-98<br>3-00-00 | 422840, Болгар ш.,<br>Пионер ур., 21<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш ш.,<br>Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |
| Тукай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | 423800, Яр Чаллы шәһәре,<br>Есенин тыкрыгы, 1<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районы социаль | (84360) | 422080, Теләче ав., Зур Тау ур., 5 |

| | | |
|---|---|---|
| яклау бүлеге | 2-18-56 | Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-29-38<br>2-50-94 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Титов ур., 26<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкого ур., 45.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-60-41<br>2-82-91 | 423950, Урыссу ш.т.п.,<br>Пушкин ур., 105/1<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>571-58-00<br>510-31-15 | 420036, Казан ш.,<br>Тимирязев ур., 8.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Вахитов районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>238-10-55<br>238-41-91 | 420043, Казан ш.,<br>Вишневский ур., 10<br>Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Киров, Мәскәү районнары социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-47-80<br>554-29-41<br><br>554-25-47<br>554-02-16<br>564-81-63 | 420102, Казан ш., Г. Баруди ур., 5<br>Usz.Kirov@tatar.ru,<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районындагы социаль яклау бүлеге | (843)<br>523-75-92<br>523-75-82 | 420124, Казан ш., Ямашев пр., 37<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Идел буе районындагы социаль яклау бүлеге | (843)<br>224-04-20<br>224-20-28 | 420110, Казан ш., Р.Зорге ур., 39 й.<br>Osz.Priv@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>272-51-79<br>273-18-06 | 420037, Казан ш., Гадел Кутуй ур., 33 й.<br>Msz.SovOR@tatar.ru». |